**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Березняк авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2023 елның 31 октябре** **№7**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Аман-Ошторма авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 14 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Аман-Ошторма авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Аман-Ошторма авылы, Ленин урамы, 22 нче йорт адресы буенча авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Аман-Ошторма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Аман-Оштырма авылы зиратын коймалау (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Аман-Оштырма авылы зиратына кораллар һәм инвентарь сатып алу;
- Аман-Оштырма авылындагы юлларны кышкы һәм җәйге чорларда карап тоту (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт өчен түләү);
-Аман-Оштырма авыл клубына җиһазлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Березняк авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Р.Ф. Шәрипов